ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш, Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш., Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 295 от «27» 09 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты каршында ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия төзү турында

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруның таралуын кисәтү турында» 1995 елның 30 мартындагы 38-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законнарын үтәү йөзеннән, «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, район халкы арасында ВИЧ-инфекция авыруларын профилактикалау, аларны иртә ачыклау һәм артыун киметү буенча кичектергесез чаралар күрү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р  б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты каршында ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2.Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга (килешү буенча):
- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш ведомствоара комиссиясе турында нигезләмә (2 нче кушымта).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче О.Н. Павлов

0000011601

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының

295 № 27.09.2022

карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты каршында ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Хуҗаҗанов М.Р. | Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе |
| Хаҗиев Д.Ф. | «Мамадыш район үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы, комиссия рәисе урынбасары |
| М.Х.Мәснәвиева | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Саба, Мамадыш, Кукмара районнарында ТО башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Галеев А.Д. | «Мамадыш район үзәк хастаханәсе» ДАССУ табиб-эпидемиологы, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Габдрахманов И.Н. | Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| Сәгыйтов Р.М. | ФКУ КП-17 начальнигы |
| Усачев Д.Б. | Мамадыш районы эчке эшләр бүлеге башлыгы |
| Ханова С.Н. | «Татмедиа» ААҖ филиалы “Мамадыш-информ” баш мөхәрир- җитәкче |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
295 № 27.09.2022
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш ведомствоара комиссиясе турында
**нигезләмә**

1. ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия (алга таба - комиссия) ВИЧ-инфекциягә қаршы көрәш мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлекне координацияләү, авыруларны профилактикалауга һәм кисәтүгә юнәлдерелгән бурычларны хәл итү буенча чараларны планлаштыру максатында булдырылган даими эшләүче киңәшү органы булып тора.

2.Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

ВИЧ-инфекция авыруларын профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чараларын эшләүдә катнашу һәм бердәм стратегия формалаштыру;

ВИЧ-инфекцияне профилактикалау буенча төп социаль, медицина, икътисадый һәм башка проблемаларны комплекслы һәрьяклап өйрәнү;

ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча максатчан программалар эшләүдә катнашу;

4.Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

Районда ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча профилактик чаралар планын эшләү,

Район дәрәҗәсендә координация механизмнарын тәэмин итү.

Җәмгыятьнең ВИЧ/СПИД белән кешеләргә карата толерант мөнәсәбәт формалаштыру. Программаларны һәм чараларны финанслауны анализлау, чаралар үткәрүне оештыру һәм җайга салу буенча тәкъдимнәр кертү.

Халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша комиссия эшчәнлегенең юнәлешләре һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү.

5. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

ВИЧ-инфекция таралуны кисәтү чараларын гамәлгә ашыру буенча Мамадыш районы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләреннән кирәкле материаллар соратып алырга;

үз утырышларында җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын, предприятие, учреждение һәм оешма җитәкчеләрен, аларның кайсы ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, ВИЧ-йогышы авыруларын профилактикалауга юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыру турында тыңларга.

җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә ВИЧ-инфекция авыруының торышы, аларның үзгәрешләрен фаразлау, профилактика чаралары, аларга каршы көрәш чаралары комплексы турында мәгълүмат бирергә;

ВИЧ-йогышы белән авыру очракларына юл куелган вазыйфаи затларны һәм гражданнарны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү өчен тиешле органнарга мәгълүмат бирергә.

6. Комиссиянең эш тәртибе:

6.1. Комиссия вәкиллекле нигездә төзелә. Комиссия составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, шулай ук башка органнар һәм оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, галимнәр, белгечләр һәм җәмәгать эшлеклеләре кушыла. Комиссия әгъзалары җәмәгать башлангычларында үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыралар һәм аның утырышларында шәхсән катнашалар. Комиссия утырышларына прокуратура, суд, эшкуарлык структуралары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре чакырылырга мөмкин. Комиссия утырышлары кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла.

6.2. Комиссия үз эшчәнлеген комиссия рәисе раслаган эш планы нигезендә башкара. Комиссия утырышын Комиссия рәисе үткәрә, ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

6.3. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы. Комиссиянең барлык карарлары комиссия әгъзаларының гомуми составының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

6.4. Комиссия карарлары аның утырышлары беркетмәләре рәвешендә рәсмиләштерелә, алар утырышта рәислек итүче тарафыннан раслана һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана. Карарлар кызыксынган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, ведомствосы нинди булуга һәм оештыру-хокукый рәвешенә карамастан, тиешле өземтә рәвешендә җиткерелә. Комиссия карарлары рекомендация характерында.